РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

28.03.2026 №110/Бк/к

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз хайваннарны аулау, тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында» 2019 елның 29 апрелендәге 202/бк/к номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Буа муниципаль районы территориясенең тиешле санитария торышын, хуҗасыз йорт хайваннарының тискәре йогынтысыннан халыкның иминлеген тәэмин итү, кеше һәм хайваннар өчен уртак йогышлы һәм инвазион авыруларны профилактикалау, күзәтүчесез хайваннар санын җайга салуның гуманлы ысулларын куллану максатларында 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон (гамәлдәге редакциядә ), «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы (2025 елның 31 июленә үзгәрешләр кертеп), «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1номерлы Россия Федерациясе Законы (2025 елның 29 декабренә үзгәрешләр кертеп) нигезендә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз хайваннарны аулау, тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында» 2019 елның 29 апрелендәге 202/бк/к номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хуҗасыз хайваннар белән мөгалләмә эшчәнлеген гамәлгә ашырганда чаралар оештыру;»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Хәмидуллин